КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 август г.Казань № 575

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Яңа автотранспорт чаралары сатып алуны стимуллаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 30 март, 204 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа автотранспорт чаралары сатып алуны стимуллаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 30 март, 204 нче карарына үзгәреш кертү хакында», 2010 ел, 28 июль, 596 нчы;

«Яңа автотранспорт чаралары сатып алуны стимуллаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 1 декабрь, 971 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа автотранспорт чаралары сатып алуны стимуллаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 30 март, 204 нче карарына үзгәреш кертү хакында», 2011 ел, 7 февраль, 75 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа автотранспорт чаралары сатып алуны стимуллаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 ел, 30 март, 204 нче карарына үзгәреш кертү хакында», 2011 ел, 6 апрель, 256 нчы;

«Автомобиль сәнәгате конструкцияләрен һәм технологияләрен модельләштерү» тармак инжиниринг үзәгенең техник йөкләмәсен һәм техник-икътисадый нигезләвен эшләү чараларын үтәүгә бәйле булган чыгымнарны өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 26 июнь, 439 нчы;

«Җитештерү белән идарә итүнең заманча технологияләрен һәм компьютерлаштырылган интеграцияләнгән җитештерүне кертү чараларын үтәүгә бәйле булган чыгымнарны өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 26 май, 354 нче;

«Бик нык турайту прессы тәҗрибә үрнәген булдыру буенча сынау проектын тормышка ашыруга бәйле булган чыгымнарны өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 20 июнь, 425 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министра
вазыйфасын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин